ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЦИПЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕПЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
15.04.2025

КАРАР
№ 46

**Чепья авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтарырга тыелган урыннарны билгеләү һәм хуҗасыз хайваннарны аларның элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеге хакында**

«Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 6.1 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2022елның 31 октябре №57 карары белән кабул ителгән «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 6 статьясы нигезендә, Чепья авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Билгеләргә:

1) Чепья авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннарны (1 нче кушымта);

2) Чепья авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны элекке яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеге (2 нче кушымта).

2. Хуҗасыз хайваннарны элекке яшәү урыннарына кайтару турында карар формасын расларга (3 нче кушымта).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Чепья авыл җирлегенең рәсми сайтында (www/baltasi.tatarstan.ru) урнаштырылган көннән үз көченә керә.

Чепья авыл җирлеге
Башкарма комитетының
җитәкчесе И.Н. Галиев

Чепья авыл җирлеге
Башкарма комитетының
15.04.2025 №46 карарына
1нче кушымта

# ЧЕПЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ХУҖАСЫЗ ХАЙВАННАРНЫ КАЙТАРУ ТЫЕЛГАН УРЫННАР

1) балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары;
2) массакүләм чаралар уздыру өчен мәйданчыклар;
3) балалар, мәгариф һәм дәвалау учреждениеләре территорияләре;
4) мәдәният объектларына якын территорияләр;
5) җәмәгать туклануы оешмаларына якын территорияләр;
6) кибетләр территорияләре;
7) зиратлар һәм мемориаль зоналар;
8) йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннар;
9) парклар территорияләре;
10) көнкүреш калдыкларын урнаштыру объектларына якын территорияләр;
11)көнкүреш калдыкларын туплау урыннары чикләрендәге территорияләр;

Чепья авыл җирлеге
Башкарма комитетының
15.04.2025 №46 карарына
2 нче кушымта

ЧЕПЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ
ХУҖАСЫЗ ХАЙВАННАРНЫ АЛАРНЫҢ ЭЛЕККЕГЕ ЯШӘҮ
УРЫННАРЫНА КАЙТАРУ ТУРЫНДА
КАРАРЛАР КАБУЛ ИТҮГӘ ВӘКАЛӘТЛЕ ЗАТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге башлыгы .
2) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге башкарма комитеты  җитәкчесе .

Чепья авыл җирлеге
башкарма комитетының
15.04.2025 № 46 карарына
3 нче кушымта

Форма

# РЕШЕНИЕ О ВОЗВРАТЕ ЖИВОТНЫХ БЕЗ ВЛАДЕЛЬЦЕВ НА ПРЕЖНИЕ МЕСТА ОБИТАНИЯ

от «____» __________ 20__г. № ______

__________________________________________________________________________

(Ф.И.О., должность лица, уполномоченного на принятие решения о возврате животных без владельцев)

на основании представленного ________________________________________
(полное наименование специализированной организации по отлову)
акта проведения освидетельствования животного без владельца на предмет наличия (отсутствия) у него немотивированной агрессивности, проведенного комиссионно с обязательным участием специалиста в области ветеринарии от «___» _______ 20___г. № ____

в отношении животного без владельца:
идентификационная метка ____________________________________________
место и дата отлова _________________________________________________,

ПРИНЯТО РЕШЕНИЕ:

__________________________________________________________________________

(о возврате животного без владельцев на прежнее место обитания/запрете возврата)

______________________________________________________________

(указывается основание принятого решения)

_______________________ _____________________________________________
(подпись) (Ф.И.О.)